**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 декабрь № 957

г. Казань

2017 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) раслагра:
Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарны;
Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарны һәм аларның күләмнәрен.
2. 2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:
«2016 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 31 декабрь, 1036 нчы;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга һәм аларның күләмнәренә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 31 март, 183 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау

турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 31 март, 189 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 10 декабрь, 933 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 13 сентябрь, 637 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы дәүләт органнарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\957.doc